ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2 ноябрь, 2022 ел № 17/7

Шәһәр Советының аерым карарларына
үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2016 елның 9 ноябрендәге 11/6 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2016 елның 15 декабрендәге 13/7, 2017 елның 15 декабрендәге 21/7, 2018 елның 21 февралендәге 23/9, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/6, 2019 елның 7 октябрендәге 33/6, 2020 елның 21 февралендәге 37/6, 2022 елның 22 августындагы 16/8 номерлы Карарлары редакциясендә), 4 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 15 пунктча белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«15) Яшәү урыны буенча Яр Чаллы шәһәрендә теркәлгән, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр – салым салу объекты милекчеләре һәм аның гаилә әгъзалары - шул ук объектта милек хокукына ия булган булган салым түләүчеләр.

Хәрби хезмәткәрнең гаилә әгъзалары булып аның белән бергә теркәлгән ире (хатыны), балалары (шул исәптән опекадагы яки попечительлектәге) һәм хәрби хезмәткәрнең ата-анасы санала.

Ташлама 2021 елның салым чорына, әлеге Карарның 2 пунктындагы 20-25, 138,139 пунктчаларында күрсәтелгән рөхсәт ителгән файдалану төрләренең берсенә караган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан җир участогына карата бирелә.

Салым түләүче түләргә тиешле сумманы билгеләгәндә, салым ташламасы, салым түләүченең теләге буенча, бер салым салу объектына бирелә.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүчеләр салым органына үзләре сайлаган салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасын бирү турында гариза тапшырмаган яисә салым ташламасын файдаланудан баш тартуы турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы, башка федераль законнар һәм әлеге Карар нигезендә салым органы алган белешмәләр нигезендә салым түләүченең салым ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап бирелә.

Салым ташламасына хокуклы салым түләүче тарафыннан сайлап алынган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырылмаган очракта салым ташламасы салым салуның максималь салым суммасына ия бер объектына карата бирелә.».

2. Шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2015 елның 22 октябрендәге 2/11 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2017 елның 15 декабрендәге 21/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/7, 2019 елның 7 октябрендәге 33/7, 2019 елның 6 декабрендәге 34/8, 2020 елның 21 февралендәге 37/7, 2021 елның 27 маендагы 7/5 номерлы Карарлары редакциясендә), 4.1 пунктны өстәп, үзгәреш кертергә:

«4.1 Яшәү урыны буенча Яр Чаллы шәһәрендә теркәлгән, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарны һәм махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләрне – салым салу объекты милекчеләрен һәм аның гаилә әгъзаларын - шул ук объектта милек хокукына ия булган булган салым түләүчеләрне физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.

Хәрби хезмәткәрнең гаилә әгъзалары булып аның белән бергә теркәлгән ире (хатыны), балалары (шул исәптән опекадагы яки попечительлектәге) һәм хәрби хезмәткәрнең ата-анасы санала.

Ташлама 2021 елның салым чорына, әлеге Карарның 2 пунктындагы 1 пунктчаның икенче абзацында, 2 пунктчада, 3 пунктчаның беренче һәм икенче абзацында күрсәтелгән һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан бер салым салу объектына карата бирелә.

Салым түләүче түләргә тиешле сумманы билгеләгәндә, салым ташламасы, салым түләүченең теләге буенча, бер салым салу объектына бирелә.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүчеләр салым органына үзләре сайлаган салым ташламасын бирү турында гариза тапшыралар, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслаучы документлар тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасына хокукы булган салым түләүче салым органына салым ташламасын бирү турында гариза тапшырмаган яисә салым ташламасын файдаланудан баш тартуы турында хәбәр итмәгән очракта, салым ташламасы Россия Федерациясе Салым кодексы, башка федераль законнар һәм әлеге Карар нигезендә салым органы алган белешмәләр нигезендә салым түләүченең салым

ташламасына хокукы барлыкка килгән салым чорыннан башлап бирелә.

Салым ташламасына хокуклы салым түләүче тарафыннан сайлап алынган салым салу объекты турында хәбәрнамә тапшырылмаган очракта салым ташламасы салым салуның максималь салым суммасына ия бер объектына карата бирелә.».

3. Әлеге Карар рәсми бастырылган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев